СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ул. Чехова, д.54, с. Верхний Услон, 422570

Чехов ур., 54 нче йорт, Югары Ослан авылы, 422570

РЕШЕНИЕ — КАРАР

17.09.2019 с. Верхний Услон № 56-282

**Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә**
**үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**
**җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты нигезендә, Югары Ослан авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Югары Ослан авыл җирлеге Советының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» № 56-280 карары, Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетының «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» 12.09.2009 ел, № 13 карары нигезендә,

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Югары Ослан авыл җирлеге**
**карар чыгарды:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче гражданнарга 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза буласызмы?:

- Югары Ослан авылының җәяүлеләр зоналарын төзекләндерү;

- Киров бистәсендә зиратка автомобиль юлы төзү ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карарны « Волжская новь» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Югары Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Совет Рәисе,**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Югары Ослан авыл җирлеге**
**Башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**